КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 2 май г.Казань № 657

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 декабрь, 997 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 декабрь, 997 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 4 октябрь, 1224 нче; 2024 ел, 26 август, 696 нчы; 2025 ел, 5 ноябрь, 907 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. Мәдәният өлкәсендә агымдагы хәлне бәяләү

«Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт программасы) Татарстан Республикасының уңышлы социаль-икътисадый һәм инновацион үсеше нигезе буларак мәдәният өлкәсен комплекслы үстерүгә юнәлдерелгән.

Дәүләт мәдәният сәясәте гармонияле рәвештә үскән һәм социаль җаваплы шәхес формалаштыру өчен рухи-әхлакый нигез буларак мәдәниятнең стратегик ролен гамәлгә ашыруга, Россия җәмгыятенең һәм Россия гражданлык үзенчәлегенең бердәмлеген ныгытуга, мәдәни эшчәнлеккә җәлеп ителгән гражданнарның санын

арттыруга һәм мәдәният өлкәсендә цифрлы ресурсларга ихтыяҗны арттыруга юнәлтелгән. Әлеге максатларга ирешү шул исәптән мәдәният өлкәсе инфраструктурасын модернизацияләү, гражданнарның һәм оешмаларның иҗади инициативаларына, мәдәни-агарту проектларына киң колачлы ярдәм күрсәтү, мәдәният өлкәсе белгечләрен яңадан әзерләү, волонтерлык хәрәкәтен үстерү һәм мәгълүмат технологияләрен кертү хисабына тәэмин ителә.

2024 елга кадәр чорга (2024 елны кертеп) дәүләт мәдәният сәясәте максатларына һәм бурычларына ирешүнең төп инструментларыннан берсе «Мәдәният» илкүләм проекты булды, ул өч федераль проекттан тора: «Мәдәни мохит», «Иҗади кешеләр» һәм «Цифрлы мәдәният».

Мәдәни байлыкны саклау, мәдәни традицияләрнең дәвамчанлыгын тәэмин итү, профессиональ сәнгатькә һәм иҗатның барлык рәвешләренә, җәмгыятьнең мәдәни потенциалын үстерүне тәэмин итә торган мәдәни инновацияләргә ярдәм итү, аларны Россиянең барлык почмакларында һәм аннан читтә күрсәтү – бу «Мәдәният» илкүләм проектының максатчан өстенлекләрен билгели торган төп билгеләр.

Татарстан Республикасында «Мәдәният» илкүләм проекты чаралары белән республика халкын колачлау өлеше 60 проценттан артык тәшкил итте. Алты ел эчендә мәдәни чараларга килүчеләр саны артты (2019 елда мәдәни чараларга килүчеләр саны – 25,7 млн.кеше, 2024 елда 103,2 млн.кеше тәшкил итте, бу база елы белән чагыштырганда 4 тапкырга артты).

2026 елга мәдәният оешмалары чараларына килүчеләр саны 88 063 меңгә кадәр җитәр дип көтелә.

«Мәдәният» илкүләм проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә гаҗәпләндерә торган нәтиҗәләргә ирешелде. Республикада миллионлаган кешегә бай һәм төрле мәдәният дөньясы ачылды. Бу музейларны, театрларны, мәдәният йортларын һәм кинотеатрларны үзгәртеп кору, шулай ук күпсанлы массакүләм чаралар уздыру нәтиҗәсендә мөмкин булды. «Мәдәни мохит» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында соңгы биш ел эчендә түбәндәге уңай структур үзгәрешләр ясалды:

Зеленодольск шәһәрендә һәм Алабуга шәһәрендә ике мәдәни үсеш үзәге төзелде;

авыл җирлегендә 27 мәдәни-ял итү учреждениесе капиталь ремонтланды һәм 27 мәдәни-ял итү учреждениесе төзелде;

18 модель китапханәләр булдырылды;

15 балалар сәнгать мәктәбе (сәнгать төрләре буенча) ремонтланды;

Буа шәһәрендә «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе реконструкцияләнде;

җиде дәүләт театры һәм муниципаль театр реконструкцияләнде һәм капиталь ремонтланды;

биш муниципаль музейга капиталь ремонт ясалды;

мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге 42 белем бирү учреждениесе музыка уен кораллары һәм методик әдәбият белән тәэмин ителде.

«Иҗади кешеләр» төбәк проекты кысаларында 2019 елдан 2024 елга кадәр акчалата бүләкләүгә грант конкурслары йомгаклары буенча 432 иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениесенә һәм муниципаль мәдәният учреждениеләренең 351 иң яхшы хезмәткәренә дәүләт ярдәме күрсәтелде.

Мәдәният өлкәсендә иҗади һәм идарәче кадрларга өзлексез белем бирү һәм аларның квалификациясен күтәрү үзәкләре базасында Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендәге 5 497 белгеч белем алды.

«Цифрлы мәдәният» төбәк проекты кысаларында 10 виртуаль концерт залы булдырылды. Республиканың барлык виртуаль залларында 904 трансляция үткәрелде, аларда 29 меңнән артык тыңлаучы булды.

2030 елга һәм 2036 елга кадәр перспективага илкүләм максатларга ирешүгә юнәлдерелгән чаралар «Гаилә» дип исемләнгән яңа илкүләм проектында каралды.

«Гаилә кыйммәтләре һәм мәдәният инфраструктурасы» федераль проектының төп күрсәткечләренә ирешү максатларында мәдәният оешмаларын: китапханәләрне, кинозалларны, балалар сәнгать мәктәпләрен, музейларны, театрларны, филармонияләрне һ.б. модернизацияләүгә, төзүгә, ремонтлауга; мәдәният-ял итү учреждениеләрен, мәдәният өлкәсендә белем бирү оешмаларын (балалар сәнгать мәктәпләрен һәм училищеларны) заманча җиһазландыруга юнәлдерелгән чараларның киң спектрын гамәлгә ашыру планлаштырыла.

2025 елда музей, китапханә, театр, клуб эшен, мәгариф, спорт, яшьләр сәясәте һәм туризм өлкәләрен берләштерә торган комплекслы мәгърифәтчелек үзәге концепциясе проекты эшләнде. Комплекслы мәгърифәтчелек үзәкләрен төзү максатлары – тарихи-мәдәни мирасның, Россия традицион кыйммәтләренең берләштерә торган ролен исәпкә алып, халыкның мәгърифәтчелек һәм мәдәни дәрәҗәсен күтәрү, Татарстан Республикасы халкын һәм кунакларын патриотик, рухи-әхлакый һәм эстетик тәрбияләү, Татарстан Республикасы музейларын һәм тарихи-мәдәни мирас объектларын популярлаштыру.

2025 – 2030 елларда муниципаль, төбәк музейлары, мәдәният йортлары һәм китапханәләр базасында балалар өчен мәдәни-аң белем бирү үзәкләрен ачу планлаштырыла.

2025 елның 1 гыйнварыннан авыл торак пунктларында, эшчеләр поселокларында, шәһәр тибындагы поселокларда, 50 меңгә кадәр кеше яшәгән шәһәрләрдә мәдәният өлкәсендә кадрлар мәсьәләсен хәл итәргә мөмкинлек бирә торган «Земство мәдәният хезмәткәре» программасы старт алды. Ул мондый торак пунктларга эшкә күчеп килүче белгечләргә 1 млн.сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләүне күздә тота.

Мәдәният хезмәткәрләренә – китапханәчеләргә, музей хезмәткәрләренә, иҗат коллективлары җитәкчеләренә, мәдәният йортлары белгечләренә, өстәмә белем бирү укытучыларына ярдәм күрсәтелә.

Программа авыл җирендәге һәм кече шәһәрләрдәге мәдәният учреждениеләренә квалификацияле кадрлар җәлеп итүне, халыкны мәдәни хезмәтләр күрсәтүдән киңрәк файдалануны тәэмин итүне, китапханә, мәдәният йортлары, театрлар һәм сәнгать мәктәпләре хезмәткәрләре белән тулысынча тәэмин итүне күздә тота.

Яшь белгечләргә ярдәм итү мәсьәләсен хәл итү максатларында Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында урнашкан дәүләт яисә муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларына эшкә кергән белгечләргә бер тапкыр бирелә торган пособиеләр каралды.

Татарстан Республикасы борынгы заманнардан Идел буеның күп кенә халыкларын формалаштыру һәм үстерү тарихын чагылдыра торган, республика һәм

гомумроссия күләмендә генә түгел, ә дөнья күләмендә дә кыйммәтле әйберләрне күрсәтә торган уникаль матди һәм матди булмаган мираска ия.

Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты (алга таба – Комитет) тарафыннан тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне ачыклау һәм өйрәнү эше дәвам ителә.

Тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне дәүләт исәбенә алу аларны мәдәни мирас объектлары реестрына кертү белән тәэмин ителә.

2026 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында:

2 026 мәдәни мирас объекты исәпләнелә, шул исәптән:

473 – федераль әһәмиятле;

1 196 – төбәк әһәмиятле;

357 – җирле әһәмиятле;

3 225 ачыклаган мәдәни мирас объекты, шул исәптән:

451 архитектура объекты;

2 774 археология объекты.

2025 елда гына Мәдәни мирас объектларының бердәм реестрына – 145 объект, ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә – 23 объект, шул исәптән моңа кадәр билгеле булмаган 11 археология объекты кертелде.

Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлегенә аерым игътибар бирелә. 2025 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән 331 мәдәни мирас объектына карата саклау зоналары расланды, шулай ук җирләрдән файдалануның тиешле режимнары һәм шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләр билгеләнде. Казан Кремле ансамбленең саклау зоналарына үзгәрешләр кертелде, шуның нәтиҗәсендә өстәмә рәвештә 19 мәдәни мирас объекты саклау зоналары белән тәэмин ителде. 2025 елда барлыгы 350 һәйкәл саклау зоналары белән тәэмин ителде.

2026 елга барлыгы саклау зоналары 1 120 мәдәни мирас объектына карата билгеләнде, бу аларга карата саклау зоналары билгеләнергә тиешле объектларның гомуми саныннан 80 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган 2024 елның 30 мартындагы Пр-616 номерлы Президентның Федераль Собраниегә Юлламасын гамәлгә ашыру йөкләмәләре исемлеген үтәү йөзеннән 2024 елның февраленнән 2025 елның декабренә кадәр 34 мәдәни мирас объекты канәгатьләнерлек булмаган хәлдән чыгарылды һәм хуҗалык әйләнешенә кертелде.

Мәдәни мирас объектларын саклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән төп чараларга шулай ук фәнни-тикшеренү, эзләнү, проект һәм җитештерү эшләрен үткәрү, фәнни җитәкчелек, әлеге эшләрне башкаруга техник һәм авторлык күзәтчелеге керә. Ел саен реставрация эшләре Татарстан Республикасында урнашкан дистәләгән мәдәни мирас объектларында бер үк вакытта алып барыла.

Археология һәйкәлләрен ачыклау һәм саклау эше Комитет тарафыннан даими рәвештә алып барыла.

2018 елдан тикшерүләр нәтиҗәсендә элек билгеле булмаган 100дән артык археология һәйкәле табылды. Әлеге объектлар ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелде.

2025 елда Алексеевск, Әлмәт, Лаеш, Чирмешән муниципаль районнарында һәм

Казан шәһәрендә урнашкан 26 археология һәйкәле федераль әһәмияттәге объектлар буларак Мәдәни мирас объектларының бердәм реестрына кертелде.

Ел саен Татарстанның археология һәйкәлләрендә тикшеренүчеләр тарафыннан фәнни ачышлар ясала һәм илебезнең фәнни тарихи базасын тулыландыра торган уникаль табылдыклар табыла.

Тарихи җирлекләрне саклап калу һәм үстерү – Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасы өлкәсендә дәүләт мәдәни сәясәтенең стратегик бурычларыннан берсе.

Татарстан Республикасында 13 тарихи җирлек исәпләнә, шуларның 2се федераль әһәмияттәге җирлекләр (Алабуга һәм Чистай шәһәрләре), 11е – төбәк әһәмиятендәге җирлек (Биләр авылы, Казан шәһәре, Болгар авылы, Бөгелмә шәһәре, Буа шәһәре, Лаеш шәһәре, Мамадыш шәһәре, Менделеевск шәһәре, Минзәлә шәһәре, Свияжск авылы, Тәтеш шәһәре). Тарихи җирлекләр белән эшләүдә комплекслы якын килүнең бурычы – социаль, мәдәни һәм икътисадый тормышны бергәләп үстерү, шулай ук аларның территорияләре үсеше белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән территориянең уңай имиджын булдыру һәм эчке һәм читтән керә торган туристлык агымнарын арттыру.

2025 елда Комитет тарафыннан 119 контроль (күзәтчелек) чара уздырылды, аларны үткәргәндә чараларны дистанцион рәвештә уздырырга мөмкинлек бирә торган «Инспектор» мобиль кушымтасы кулланыла. Кызыксынучы зат мәдәни мирас объектын саклау өлкәсендә теләсә нинди мәгълүматны мобиль кушымта буенча алырга мөмкин.

Контроль-күзәтчелек эше өлкәсендә профилактик визит үзара хезмәттәшлекнең төп механизмына әверелә. 2025 ел дәвамында Комитет тарафыннан 247 профилактик чара гамәлгә ашырылды. Әлеге чаралар закон таләпләрен үтәүне стимуллаштыруга һәм хокук бозулар куркынычын киметүгә, хокук ияләренә тармак мәсьәләләре буенча консультация ярдәме күрсәтүгә, потенциаль хаталар турында алдан хәбәр итүгә һәм урыннарда аларны булдырмауга ярдәм итүгә юнәлдерелде.

Илнең бердәм мәдәни-мәгариф киңлеген үстерүгә, шулай ук Россиянең дөньякүләм гуманитар һәм мәдәни киңлектә ролен күтәрүгә, шул исәптән укучыларның иҗади фикерләвен үстерүгә, креатив индустрияләр өлкәсендә һөнәрләрне, белгечлекләрне һәм әзерлек юнәлешләрен популярлаштыруга һәм үстерүгә ярдәм итүче иң мөһим юнәлешләрнең берсе – ул «Россиядә уйлап чыгарылды» федераль проекты кысаларында креатив индустрияләр мәктәбен булдыру.

Татарстан Республикасында мондый мәктәпләр «Н.И.Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе (техникум), Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «1 нче балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе һәм «С.Сәйдәшев исемендәге Түбән Кама музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында булдырылды.

Татарстан Республикасында мәдәният оешмаларыннан һәркем файдалана алуны арттыру өчен 14 яшьтән 22 яшькә кадәрге яшьләргә социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән «Пушкин картасы» программасы актив гамәлгә ашырыла.

2024 елда республиканың 321 000 артык яшьләре проектта катнашты.

Статистика мәгълүматларына караганда, карта чыгаручылар саны буенча рейтингта Татарстан Республикасы Россия төбәкләре арасында Мәскәү шәһәреннән (949 000), Санкт-Петербург шәһәреннән (582 000) һәм Краснодар краеннан (340 000) кала 4 урында тора.

Катнашучылар өлеше буенча Татарстан Республикасы Санкт-Петербург шәһәреннән (121,16 процент) кала 2 нче урында (88,99 процент) тора.

Шуңа карамастан, мәдәният өлкәсендә күп проблемалалар хәл ителмәгән булып кала, шул исәптән:

мәдәният өлкәсендә квалификацияле кадрлар, шулай ук мәдәни мирас объектларында, музейлар һәм китапханәләр фондларында реставрация эшләрен башкару өчен белгечләр җитмәү;

мәдәният өлкәсендә эшчәнлек башкаручы дәүләткә карамаган структураларның, шул исәптән коммерциягә карамаган оешмаларның мөмкинлекләре җитәрлек дәрәҗәдә файдаланылмау, алар белән Татарстан Республика дәүләт мәдәният оешмалары арасындагы үзара хезмәттәшлек формалары үсеш алмау һәм, шуңа бәйле рәвештә, дәүләткә карамаган (иҗтимагый, коммерциягә карамаган, хосусый) оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган мәдәният өлкәсендәге хезмәт күрсәтүләр җитәрлек дәрәҗәдә үсеш алмау.

Әлеге проблемаларны хәл итү дәүләт сәясәтенең өстенлекләре һәм максатлары нигезендә мәдәният өлкәсе үсешен тәэмин итәчәк һәм Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешүгә сизелерлек йогынты ясаячак.»;

II бүлектә:

беренче абзацта татар текстында «б-2765 номерлы боерыгы» сүзләрен «, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 12 декабрендәге б-3773 номерлы карары белән расланган «2025 – 2045 еллар чорына «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын саклау» программасы,» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«5 нче максат: мәдәни һәм тарихи мирасны хәзерге һәм киләчәк буыннар мәнфәгатьләрендә саклау, мәдәни мирас объектларын канәгатьләнерлек хәлгә китерү һәм хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү чараларын гамәлгә ашыру.»;

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «III. Стратегик өстенлекләр, илкүләм максатлары һәм Стратегия-2030 максатлары, Россия Федерациясе дәүләт программалары күрсәткечләре белән үзара бәйләнеш турында белешмәләр

Татарстан Республикасы дәүләт программасының максат билгеләү системасы һәм бурычлары Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга кадәр перспективага Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указын, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В.Мишустинның 2024 елның 30 декабрендәге ММ-П13-47086 номерлы резолюциясе белән расланган 2030 елга кадәр һәм 2036 елга кадәр перспективага Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча бердәм планны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 12 декабрендәге б-3773 номерлы боерыгы белән расланган «2025 – 2045 еллар чорына «Россия

Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын саклап калу» программасын, шулай ук Стратегия-2030 исәпкә алып булдырылды.

Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә юнәлдереләчәк:

«Талантларны үзреализацияләү һәм үстерү өчен мөмкинлекләр» 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатына ирешүгә;

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын саклап калу» программасын һәм 2025 – 2045 еллар чорына программаны гамәлгә ашыру чаралары планын тормышка ашыру;

Стратегия-2030ның «Татарстан-2030 – глобаль конкурентлыкка сәләтле тотрыклы төбәк, «Идел-Кама» үсеш полюсы драйверы. Татарстан – кеше капиталының, институтларның, инфраструктураның, икътисадның, тышкы интеграциянең (Россиянең үзәк Евразия регионы) һәм эчке пространствоның үзара бәйләнгән үсеше сыйфаты буенча лидер; үсеш темплары алдан бара торган, хезмәтнең халыкара бүленешенә керү дәрәҗәсе югары булган төбәк» дигән төп стратегик максатын гамәлгә ашыруга, шулай ук «Кеше капиталы: тупланган кеше капиталы Татарстан Республикасының конкурентлык сәләтен тәэмин итә. Татарстан Республикасы яшәүнең югары сыйфатына ирешү шартларын тудыру аша төп актив буларак кеше капиталын туплауда алдынгы булып тора» дигән Стратегия-2030ның стратегик максатын гамәлгә ашыруга.»;

IV бүлеккә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Мәдәни һәм тарихи мирасны хәзерге һәм киләчәк буыннар мәнфәгатьләрендә саклау, мәдәни мирас объектларын канәгатьләнерлек хәлгә китерү һәм хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү чараларын гамәлгә ашыру» максатына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен башкару һәм мәдәни мирас объектларын саклап калуга стимуллар системасын булдыру;

мәдәни мирас объектлары реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларының гомуми санында канәгатьләнерлек булмаган яисә җимерелгән хәлдәге мәдәни мирас объектлары өлешен киметү;

мәдәни мирас объектларын ташламалы бәядән хосусыйлаштыру;

тарихи җирлекләр территорияләре чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне раслау.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин